**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная **ур**, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 04.02.2020** **№ 166**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты » МКУсендә хезмәтне саклау белән идарә итү системасы нигезләмәсен раслау турында**

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының 2016 нчы елның 19 нчы августыннан 438н номерлы “Хезмәтне саклау белән идарә итү системасының Типовой нигезләмәсен раслау турындагы” боерыгына нигезләнеп КАРАР ИТӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсендә хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең эшләр белән идарә итүчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

«Расланды»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 нче елның 4 нче
февраленнән 166 нчы
номерлы карары белән

«Килешенде»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советының һәм Татарстан
Республикасы Биектау
муниципаль районы
Башкарма комитетының
Берләштерелгән профсоюз
оешмасы рәисе
___________Е.М. Денисова
4 нче февраль 2020 нче ел

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсендә хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсендә хезмәтне саклау белән идарә итүнең системасы турында Нигезләмә (ары – Нигезләмә) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” МКУсендә (ары – Башкарма комитет) хезмәтне саклау белән идарә итүне формалаштыруның төп принципларын һәм структурасын, аның функцияләрен билгели һәм Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы һәм башка норматив хокукый актларга нигезләнә.
2. Башкарма комитетта хезмәтне саклау белән идарә итү системасы (ары – Система) Башкарма комитет һәм аның структур бүлекчәләренең (юридик зат оештырмыйча) (ары – структур бүлекчәләр) хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең гомерләрен һәм сәламәтлекләрен саклауга, хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән бердәм эшчәнлекнең оештыру формалары һәм методлары җыелмасын тәшкил итә.
3. Система кысаларында Башкарма комитетта хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча идарә итү һәм көйләү баскычлары булып Башкарма комитетның структур бүлекчәләре, Башкарма комитетның хезмәтне саклау өчен җаваплы кешесе һәм җитәкче санала.

## II. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендә сәясәте

1. Башкарма комитетның хезмәтне саклау буенча сәясәте (ары – хезмәтне саклау буенча сәясәт) Башкарма комитет тарафыннан хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләрен үтәү буенча бурычларын һәм үзенә ирекле рәвештә кабул иткән йөкләмәләрен үтәүне гарантияли.

2. Хезмәтне саклау буенча сәясәт түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген аларның хезмәт эшчәнлеге процессында саклауның өстенлеген;

б) эш урыннарында хезмәт шартларының хезмәт саклавы таләпләренә туры килүен;

в) хезмәткәрләрнең сәламәтлеге начарлану хәлләрен һәм очракларын, җитештерүдә травма алу һәм һөнәри авыруларны, шул исәптән һөнәри куркынычлык белән идарә итү аркылы кисәтү буенча эзлекле һәм өзлексез чаралар (чара күрүләрне) үтәүне;

г) хезмәткәрләрнең шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алуны, шул исәптән эш урыннарын проектлаштыру, җиһазлар, инструментлар, чимал һәм материаллар, шәхси һәм коллектив саклану чаралары сайлау, җитештерү һәм технологик процессларны төзү аркылы;

д) Системаның туктаусыз камилләшүен һәм эффективлыгын күтәрүне;

е) хезмәткәрләрне һәм алар тарафыннан вәкаләтләнгән вәкиллек органнарын хезмәтне саклау белән идарә итүдә һәм хезмәтне саклау таләпләренә туры килгән хезмәт шартларын тәэмин итүдә катнашуга, мондый катнашуларны кирәкле ресурслар белән тәэмин итеп һәм кызыксындыру чаралары аркылы мәҗбүри җәлеп итү;

ж) хезмәт шартларының куркынычсызлыгын тәэмин итүдә мөмкин булган кадәр шәхси кызыксынуны;

з) үз эшчәнлегенең үзенчәлекләреннән чыгып, хезмәт саклавы өлкәсендәге башка бурычларны үтәүне .

## III. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендәге максатлары

1. Хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең төп максатлары (ары – максатлар) хезмәтне саклау буенча сәясәттә саклананалар һәм әлеге нигезләмәнең V бүлегендә каралган чаралар эш бирүче тарафыннан гамәлгә ашырылып ирешеләләр.

2. Системаның төп максатлары:

а) хезмәтне саклау өлкәсендә сәясәтнең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыру һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәрне эшкәртү;

б) хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча программа эшләү һәм аны гамәлгә ашыру;

в) хезмәтне саклау буенча законнарны үтәүне тәэмин итүче шартлар тудыру, шул исәптән хезмәт процессында файдаланыла торган биналарны һәм корылмаларны, хезмәт процессының җиһазларын, приборларын һәм техник чараларын эксплуатацияләүнең куркынычсызлыгын тәэмин итү;

г) хезмәтнең куркынычсыз шартларын формалаштыру;
д) хезмәтне саклау таләпләрен үтәүне контрольләү;
е) хезмәтне саклау буенча укыту һәм белемнәрне тикшерү, шул исәптән хезмәтне саклау өлкәсендә өзлексез белем системасын булдыру һәм камилләштерү;
ж) Башкарма комитетта хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар белән бәхетсезлек очраклары килеп чыгуны кисәтү;
з) Башкарма комитетта хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы персоналның, затларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларга дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтү, хезмәт, җитештерү процессы, оештырулы ял итү режимнарын оптималь чиратлаштыруны булдыру.

## IV. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары арасында хезмәтне саклау өлкәсендә вазыйфаларны билгеләү

1. Башкарма комитет:
а) хезмәтне саклау таләпләренә туры килгән хезмәт шартларын тәэмин итүне кертеп, хезмәткәрләрнең хезмәтне саклауга хокукларын гарантияли;
б) хезмәткәрләрнең хезмәт һәм ял режимы үтәлүен тәэмин итә;
в) хезмәткәрләрне үз вакытында җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан, һөнәри куркынычлыклардан иминиятләүне тәэмин итә;
г) хезмәтне саклау буенча чараларны ресурслар белән тәэмин итүне оештыра;
д) җитештерү биналарын, корылмаларны, җиһазларны куркынычсыз эксплуатацияләүне, технологик процессларның һәм җитештерүдә кулланыла торган чимал һәм материалларның куркынычсызлыгын булдыра;
е) Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә үз акчалары хисабына мәҗбүри алдан карау (эшкә урнашканда) һәм вакытлы (хезмәт эшчәнлеге агымында) медицина күзәтүләрен оештыра;
ж) хезмәтне саклауны тәэмин итүгә кагылышлы хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен кирәкле компетенцияләр дәрәҗәсен саклау кирәклеген исәпкә алып, хезмәтне саклау буенча әзерлекне дә кертеп, хезмәткәрләрнең белем алуы һәм һөнәри әзерлек үтүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә;
з) күрсәтелгән эшкә медицина каршылыклары булмаган һәм тиешле квалификация таләпләрен канәгатьләндерүче затларны мөстәкыйль эшләүгә үткәрә;
и) коллектив саклану чараларын булдыруны һәм эшләтүне тәэмин итә;
к) хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне оештыра;
л) хезмәткәрләргә аларның эш урыннарында хезмәт шартлары, һөнәри куркынычлылыклар дәрәҗәсе, шулай ук аларга каралган гарантияләр, тиешле компенсацияләр турында мәгълүмат җиткерүне гамәлгә ашыра;
м) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә хезмәткәрләргә санитар-көнкүреш хезмәте һәм медицина белән тәэмин итүне булдыра;
н) һәлакәт, бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларның сәбәпләрен ачыклауда катнаша, күрсәтелгән сәбәпләрне бетерү, аларны кисәтү һәм профилактикалау буенча чаралар күрә;
о) дәүләт хакимияте органнарына килеп чыккан һәлакәтләр, бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар турында вакытында хәбәр итә;

п) дәүләт хакимияте органнарының контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан бирелгән күрсәтмә һәм боерыкларын башкаруны оештыра.

2. Башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфалары:
а) хезмәтне саклау инструкцияләрен, эчке хезмәт тәртибен, шулай ук технологик һәм хезмәт дисциплинасын үтәүне, эшләр җитәкчесенең күрсәтмәләрен үтәүне дә кертеп, үзенең хезмәт функцияләрен башкару кысаларында хезмәт саклавы таләпләрен үтәүне тәэмин итә;
б) эш бирүче юлламасы буенча медицина күзәтүе, психиатр таныклавын, химик-токсикологик тикшеренүләр үтә;
в) хезмәт саклавы буенча, шулай ук җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча әзерлек үтә;
г) хезмәт шартлары һәм саклавы торышын контрольләүдә катнаша;
д) үзенең эш урынын чисталыкта тота;
е) эш сменасы (эш көне) башланыр алдыннан үзенең эш урынын карап чыга;
ж) үзенең эш урынында җиһазлар һәм инструментларның төзеклеген карап тора;
з) үзенең эш урынына карата киртәләүнең, саклау җайланмаларының, блокировкалау һәм сигнализация корылмаларының, шәхси һәм коллектив саклану чараларының, үтү, күчү, мәйданчыклар, баскыч җайланмалары, тотынгычлар булуын һәм аларның төзеклеген, шулай ук аларның чүпләнүен һәм әйберләр белән тыгызлануын тикшерә;
и) үзенең эш урынын карап чыкканда ачыкланган кимчелекләр турында үзенең турыдан-туры җитәкчесенә хәбәр итә һәм аның күрсәтмәләре нигезендә эш итә;
к) хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүче шәхси һәм коллектив саклану чараларын һәм җайланмаларын дөрес файдалана;
л) үзенең турыдан-туры яки югарырак торучы җитәкчесен кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыручы теләсә нинди ситуация һәм бәхетсезлек очрагы яки үзенең я башка затларның сәламәтлеге начарлану, шул исәптән һөнәри авыру билгеләренең кисәк килеп чыгуы (агулану) турында хәбәр итә;
м) һәлакәтләр килеп чыкканда, эш бирүче тарафыннан алдан расланган, алар килеп чыккан очракта эш итү тәртибе буенча һәлакәтнең зураюын чикләү һәм аны бетерү өчен чаралар күрә.

10. Хезмәтне саклау буенча белгеч:
а) Системаның эшләвен тәэмин итә;
б) эш бирүчедә хезмәтне саклау буенча оештыру эшләре белән җитәкчелекне гамәлгә ашыра, эш бирүченең структур бүлекчәләре эшләренә юнәлеш бирә;
в) хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрү өчен уңайлы урыннарга күрсәтмә әсбаплар һәм заманча техник чаралар урнаштыруны оештыра;
г) Россия Федерациясенең Хезмәт Кодексына нигезләнеп, хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау өлкәсендәге норматив-хокукый документлар белән тәэмин ителешен контрольләүне гамәлгә ашыра;
д) эш бирүчедә хезмәтне саклау таләпләренең, Хезмәт законнарының хезмәтне саклау , хезмәт һәм хезмәткәрләрнең ял режимы бүлекләренең, дәүләт хакимияте

органнарының контроль-күзәтчелек чараларының нәтиҗәләре буенча күрсәтмә һәм боерыклары үтәлешенә контрольлек итә;
е) хезмәт шартлары һәм саклавы торышына контрольне гамәлгә ашыра;
ж) эш бирүченең структур бүлекчәләре тарафыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау буенча чаралар эшләүне оештыра һәм аларның үтәлешен контрольдә тота;
з) дәүләт хакимияте органнары белән хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча оператив һәм консультатив элемтә булдыра;
и) хезмәтне саклау буенча локаль актларны эшләү һәм яңадан карауда катнаша;
к) хезмәтне саклау буенча әзерлекне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;
л) шәхси һәм коллектив саклану чаралары белән тәэмин итүне, бирү, саклау һәм файдалануны, аларның төзеклеген һәм дөрес куллануны контрольдә тота;
м) махсус кием һәм башка шәхси саклану чараларының, юучы һәм зарарсызландыручы матдәләрнең, сөтнең, дәвалау-профилактик туклану бирелүнең, эш көненең озынлыгы нормаларын үзгәртү буенча, шулай ук хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча хезмәт хакы күләмен һәм түләүле ял озынлыгын арттыру буенча тәкъдимнәр карый һәм кертә;
н) хезмәт шартларына махсус бәяләүне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;
о) һөнәри куркынычлылык белән идарә итүдә катнаша;
п) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә хезмәтне саклау торышын тикшерүләрне оештыра һәм үткәрә ;
р) медицина күзәтүләрен, психиатр таныклавын, химик-токсикологик тикшеренүләрне үткәрүне оештыра ;
с) булган хезмәт саклавы таләпләрен бозуларны һәм кимчелекләрне бетерү буенча күрсәтмәләр (боерыклар) бирә, аларның үтәлешен контрольдә тота;
т) һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авырулар тикшерүдә катнаша.

11. Структур бүлекчә җитәкчесе:
а) эш бирүченең структур бүлекчәсендә хезмәт шартларының хезмәтне саклау таләпләренә туры килүен тәэмин итә;
б) Системаның эшләвен тәэмин итә;
в) хезмәтне саклау өлкәсендә аңа йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык тота;
г) үзенең буйсынучылары арасында хезмәт саклавы өлкәсендәге вазыйфаларны бүлә, шул исәптән аларга үзенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшыра һәм аларның җаваплылык дәрәҗәсен билгели;
д) хезмәтне саклау буенча вәкиллекле органнар хезмәткәрләре тарафыннан вәкаләтләнгән комитетның (комиссиянең) эшенә ярдәм итә;
е) эш бирүче акчалары исәбенә структур бүлекчә хезмәткәрләренең үз вакытында мәҗбүри алдан (эшкә урнашканда) һәм вакытлы (хезмәт эшчәнлеге агымында) медицина күзәтүләрен, психиатр таныклавын, химик-токсикологик тикшеренүләр үткәрүне тәэмин итә;
ж) күрсәтелгән эшкә медицина каршылыклары булмаган һәм тиешле квалификация таләпләрен канәгатьләндерүче затларны мөстәкыйль эшләүгә үткәрә;
з) хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрүне оештыра;

и) махсус өс киеме, махсус аяк киеме һәм башка шәхси саклану чараларын, юучы һәм зарасызландыручы чараларны бирүне оештыра;
к) структур бүлекчәнең тиешле контингент хезмәткәрләрен дәвалау-профилактика туклануы, сөт белән тәэмин итүне оештыра ;
л) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә хезмәткәрләргә санитар-көнкүреш хезмәте һәм медицина белән тәэмин итүне булдыра;
м) структур бүлекчәдә житештерү биналарын, корылмаларны, җиһазларны куркынычсыз эксплуатацияләүне, технологик процессларның һәм җитештерүдә кулланыла торган чимал һәм материалларның куркынычсызлыгын булдыра;
н) хезмәт шартларына махсус бәяләүне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;
о) һөнәри куркынычлыклар белән идарә итүдә катнаша;
п) структур бүлекчәләрдә хезмәтне саклау торышын тикшерүләрне оештыра һәм үткәрүдә катнаша;
р) структур бүлекчәдә һәлакәтләрне булдырмау буенча, мондый хәлләр килеп чыкканда структур бүлекчә хезмәткәрләренең һәм башка затларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларын, шул исәптән һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрә;
с) структур бүлекчәдә килеп чыккан һәлакәт, бәхетсезлек очракларын һәм структур бүлекчә хезмәткәрләренең һөнәри авырулары сәбәпләрен ачыклауда катнаша, күрсәтелгән сәбәпләрне бетерү, аларны кисәтү һәм профилактикалау буенча чаралар күрә
т) структур бүлекчәдә килеп чыккан һәлакәт, бәхетсезлек очрагы, һәм структур хезмәткәрләренең һөнәри авырулары турында эш бирүчегә вакытында хәбәр итә;
у) дәүләт хакимияте органнарының контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан бирелгән күрсәтмә (боерыкларын), хезмәтне саклау хезмәтенең (белгеченең) күрсәтмәләрен (боерыкларын) башкаруны оештыра;
ф) структур бүлекчәдә җитештерү процессларын контрольләү өчен кирәкле приборлар һәм системаларның булуын һәм эшләвен тәэмин итә;
х) хезмәт саклавы таләпләрендә билгеләнгән очраклар килеп чыкканда, структур бүлекчәдә эшләрне туктата;
ц) структур бүлекчәнең уңайлы урыннарында, структур бүлекчә хезмәткәрләрен һәм башка затларны таныштыру өчен, хезмәт саклавы таләпләрен эченә алган документ һәм мәгълүматларның булуын тәэмин итә;
ч) структур бүлекчәдә килеп чыккан һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары вакытында ашыгыч медицина ярдәме чакыру һәм зыян күрүчеләрне медицина оешмаларына җиткерүне оештыру буенча чаралар күрә.

## V. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендә максатларга ирешүгә юнәлтелгән процедуралары

1. Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештыру максатыннан эш бирүче түбәндәгеләрне билгели:
а) хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау буенча кирәкле һөнәри компетентлыгына таләпләрен, аны тикшерүне, саклауны һәм үстерүне ;

б) хезмәтне саклау буенча стажировка үтүче, аның һәр һөнәр (вазыйфа) буенча дәвамлыгын күрсәтеп, хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалар) исемлеген ;
в) хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә рөхсәт алган оешмаларда хезмәтне саклау буенча әзерлек үтүче хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеген;
г) хезмәтне саклау буенча әзерлекне эш бирүчедә үтүче хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;
д) эш урынында беренчел инструктажны үтүдән азат ителгән хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;
е) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә эш урынында хезмәтне саклау буенча инструктаж үткәрү өчен, хезмәтне саклау буенча стажировка үткәрү өчен җаваплы хезмәткәрләрне ;
ж) хезмәтне саклау буенча инструктаж программасына кертелгән сорауларны;
з) эш бирүченең хезмәтне саклау таләпләре буенча белемнәрне тикшерү комиссиясе составын;
и) эш бирүченең хезмәтне саклау таләпләре буенча белемнәрне тикшерү комиссиясе эшенең регламентын;
к) эш бирүче комиссиясендә хезмәткәрләр үтә торган хезмәтне саклау буенча белемнәрне тикшерү сорауларының исемлеге;
л) җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча әзерлек оештыруның тәртибен ;
м) хезмәтне саклау буенча инструктаж оештыру һәм үткәрү тәртибен;
н) эш урынында стажировка һәм хезмәтне саклау буенча әзерлекне оештыру һәм үткәрү тәртибен.
2. Эш бирүче хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештырганда, хезмәткәрләрне әзерләү мөһимлеген алар башкара торган эшләрнең характерыннан һәм эчтәлегеннән чыгып, хезмәткәрләргә үзләренең вазыйфа йөкләмәләрен куркынычсыз үтәү өчен кирәкле квалификацияләре һәм компетентлыгыннан чыгып исәпкә ала.
3. Хезмәт шартларын бәяләүне оештыру һәм үткәрү процедурасын оештыру максатыннан эш бирүче үзенең эшчәнлек үзенчәлекләреннән чыгып түбәндәгеләрне билгели:
а) хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү буенча комиссия оештыру һәм эшләтү тәртибен, шулай ук аның әгъзаларының хокуклары, вазыйфалары һәм җаваплылыгын;
б) эш бирүченең аерымланган структура бүлекчәләре булганда, хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү комиссиясенең эшләү үзенчәлекләре;
в) комиссия эшчәнлегенең хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү өлешендә эш бирүченең эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрүнең оештыру тәртибен;
г) Эш бирүченең эшчәнлеге төренә карата бу эшкә компетентлырак оешманы җәлеп итәргә кирәклеген исәпкә алучы, хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрә торган оешма белән гражданлык-хокукый килешүгә сайлау һәм төзүнең тәртибен;
д) хезмәт шартларын махсус бәяләү мәсьәләләре буенча бәхәсләрне көйләү тәртибен;
е) хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләрен куллану тәртибен.

4. Һөнәр куркынычлыклары белән идарә итү процедурасын оештыру максатыннан эш бирүче үзенең эшчәнлеге үзенчәлекләреннән чыгып һөнәри куркынычлыклар белән идарә итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруның тәртибен билгели:
а) куркынычлыкларны ачыклау;
б) һөнәри куркынычлыкларның дәрәҗәсен бәяләү;
в) һөнәри куркынычлык дәрәҗәләрен киметү.

## VI. Процедураларны гамәлгә ашыру буенча чараларны планлаштыру

5. Процедураларны гамәлгә ашыру буенча чараларны планлаштыру максатыннан эш бирүче процедураларны гамәлгә ашыру буенча чаралар планын (ары – План) әзерләү, яңадан карау һәм актуальләштерү тәртибен билгели.

6. Планда түбәндәгеләр чагыла:

а) хезмәтне саклау комитеты (комиссиясе) (булганда) яки эш бирүче тарафыннан үткәрелгән эш бирүчедә хезмәт шартлары һәм аны саклау торышын анализлау нәтиҗәләре;

б) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларның гомуми исемлеге;

в) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чараның көтелгән нәтиҗәләре;

г) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чараның гамәлгә ашыру срогы;

д) процедураларны гамәлгә ашырганда чараларны үткәрү өчен идарәнең һәр дәрәҗәсендә җаваплы затлар;

е) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны финанслау чыганагы.

## VII. Система эшенә контроль һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглау

7. Системаның эшләвен контрольләүне оештыру һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглау максатларында эш бирүче чараларны гамәлгә ашыруның түбәндәгеләрне тәэмин итүче тәртибен билгели:
а) хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышы үтәлергә тиешле хезмәтне саклау таләпләренә, хезмәтне саклау килешүләренә туры килүен бәяләү;
б) процедураларның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын билгеләү өчен мәгълүмат алу;
в) Системаны камилләштерү буенча карарлар кабул итү өчен нигез булып торган мәгълүматлар алу.

8. Эш бирүче Системаның эшләвен контрольләүнең һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглауның, аларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин булган төп төрләрен билгели:
а) эш урынының, кулланыла торган җиһазларның, инструментларның, чималның, материалларның, хезмәткәр тарафыннан гамәлгә ашырылучы технологик процесслар кысаларында эшне үтәүнең торышын, һөнәри куркынычлыкларны ачыклау, шулай ук һәрвакыт башкарыла торган хезмәтне саклау буенча башка чараларны гамәлгә

ашыруның торышын контрольләү, процедураларны гамәлгә ашыруның күрсәткечләрен мониторинглау;
б) үтәлүе вакытлы булган процессларны контрольләү: хезмәткәрләрнең эш шартларын бәяләү, хезмәтне саклау буенча әзерлек, медицина күзәтүләре, психиатр таныкламалары, химик-технологик тикшеренүләр үткәрү;
в) һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны, шулай ук хезмәтне саклау таләпләрендәге үзгәрешләрне, хезмәтне саклау буенча үтәлергә тиешле килешүләрне, яңа технологик процессларны, җиһазларны, инструментлар, чимал һәм материаллар үзгәрешен яки кертелүен исәпкә алу һәм анализлау;
г) гомумән Система эшенең эффективлыгын контрольләү.
9. Система эшен контрольләүнең һәм идарә итүнең һәр дәрәҗәсендә процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауның эффективлыгын күтәрү өчен, эш бирүче Система эшен контрольләүнең һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауның баскычлы формаларын кертә, шулай ук Система эшен контрольләүнең һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауның җәмәгать контролен тормышка ашыру мөмкинлеген күздә тота.

VIII. Система эшен яхшыртуларны планлаштыру
1. Система эшен яхшыртуны планлаштыруны оештыру максатыннан, эш бирүче Система эшен яхшыртуны Система эшен контрольләү һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләренә бәйле итеп куя, шулай ук һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны тикшерүләрнең нәтиҗәләрен, дәүләт хакимияте органнарының контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләрен, хезмәткәрләрнең һәм (яки) алар тарафыннан вәкаләт бирелгән вәкиллекле органнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу мәҗбүри.
2. Системаның эшен яхшыртуны планлаштырганда эш бирүче система эшенең эффективлыгына түбәндәге күрсәткечләрне бәяләүне күздә тоткан анализ үткәрә:
а) хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең максатларга ирешү дәрәҗәсе;
б) Системаның хезмәтне саклау Сәясәтендә чагылган эш бирүче вазыйфаларын үтәүне тәэмин итү сәләте;
в) Система эшенең эффективлыгын алдагы анализ нәтиҗәләре буенча идарәнең бөтен дәрәҗәләрендә эш бирүче билгеләгән гамәлләрнең эффективлыгы;
г) хезмәтне саклау өлкәсендә максатларга төзәтмәләр кертүне, хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең вазыйфалы затларының вазыйфаларын яңадан бүлүне, эш бирүченең ресурсларын яңадан бүлүне дә кертеп, Системаны үзгәртергә кирәклеге;
д) Системаны үзгәртү турындагы карар кагылган хезмәткәрләрнең вакытында әзерлеген тәэмин итү мөһимлеге ;
е) Система эшенең эффективлыгын бәяләүнең критерийларын үзгәртергә кирәклеге.

**IX. Һәлакәтләргә, бәхетсезлек очракларына һәм һөнәри авыруларга карата чаралар күрү (реакция)**

1. Куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү һәм саклау, җитештерүдә травма алу һәм һөнәри авыру очракларын булдырмау максатыннан эш бирүче һәлакәтләр

килеп чыгуның потенциаль мөмкинлеген, алар килеп чыкканда үткәрелә торган гамәлләр тәртибен билгели.

2. Һәлакәтләр килеп чыкканда үткәрелә торган гамәлләр тәртибен билгеләгәндә эш бирүче тарафыннан һәлакәтләргә каршы тору һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүнең гамәлдәге һәм яңа эшләнә торган планнары, шулай ук һәлакәт очрагында түбәндәгеләрне гарантияләү мөһимлеге исәпкә алына:

а) һәлакәт килеп чыкканда эш зонасындагы кешеләрне эчке элемтә системасы чаралары һәм һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү буенча гамәлләрне координацияләү ярдәмендә саклау;

б) хезмәткәрләрнең эшне туктату һәм (яки) эш урынын ашыгыч калдырып куркынычсыз урынга юнәлергә мөмкинлеге;

в) һәлакәт шартларында эшне башламау;

г) һәлакәт турында тиешле компетентлы органнарга, һәлакәт һәм гадәттән тыш ситуацияләрне бетерү хезмәтләре һәм бүлекләренә мәгълүмат тапшыру, эш бирүченең алар белән ныклы элемтәсе;

д) җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү, кирәк булганда ашыгыч медицина ярдәмен чакырту (эш бирүченең сәламәтлек пункты булганда беренче ярдәм күрсәтү), янгынга каршы чаралар күрү эш зонасындагы бөтен кешене эвакуацияләү;

е) хезмәткәрләрне һәлакәтләрне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен әзерләүне, чын һәлакәтләргә якынлаштырылган шартларда даими тренировкалар үткәрүне дә кертеп, һәлакәтләргә әзерлекне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә әзерлекне тәэмин итү.

## X. Системаның документлары белән идарә итү

1. Системаның документлары белән идарә итүне оештыру максатыннан эш бирүче системаның структурасын, хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең һәр структур бүлекчәсе һәм һәр конкрет башкаручысы өчен бурычлар һәм җаваплылыкны, хезмәтне саклау һәм контрольләүне тәэмин итүче процессларны, Системаның эшләвен тәэмин итүче эш бирүче бүлекләре арасында кирәкле элемтәне үз эченә алган локаль актларны һәм башка документларны формалаштыру буенча форма һәм рекомендацияләрне билгели.

2. Система документларын эшләү һәм раслау өчен җаваплы затлар эш бирүче тарафыннан бөтен идарә итү дәрәҗәләрендә билгеләнә. Эш бирүче тарафыннан шулай ук Системаның документларын эшләү, килештерү, раслау һәм яңадан карау тәртибе, аларны саклау сроклары билгеләнә.

3. Системаның яңадан карауга, актуальләштерүгә, яңартуга һәм үзгәртүгә карамаган махсус төр документлар сыйфатында Системаның контроль-исәп документлары (язмалар), түбәндәгеләрне кертеп билгеләнә:

а) Системаны гамәлләштерүдән туган актлар һәм башка мәгълүматлар язмалары;

б) һәлакәтләр, бәхетсезлек очраклары, һөнәри авырулар турында мәгълүматларны исәпкә алу журналлары һәм акт язмалары;

в) хезмәткәрләргә җитештерү тирәлегенең һәм эш процессының зыянлы (куркыныч) факторлары тәэсире турында һәм хезмәткәрләрнең эш шартлары һәм сәламәтлекләрен күзәтүләр турындагы язмалар;

г) Система эшен контрольләү нәтиҗәләре.